Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXIII-4**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 4 сентябре

Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль район Советы депутаты статусы хакындагы Нигезләмәне раслау турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга һәм Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы Уставына тәңгәлләштерү максатларында, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 45-ЗРТ номерлы законына, Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы Уставына туры китереп, Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль район Советы депутаты статусы турындагы кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга;

2.Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсемуниципаль районСоветының 2014 елның 28 мартындагы “Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсемуниципаль районСоветы депутаты статусы хакындагы Нигезләмәне раслау турында”гы XXXVI-3 номерлы карары көчен югалткан дип танырга;

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2018 елның 4 сентябрендәге
XXXIII-4 номерлы карары белән
расланды

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районСоветы депутаты статусы турында Нигезләмә

**1маддә. Балык Бистәсе муниципаль район Советы депутаты статусының хокукый нигезе**

1.Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль район Советыдепутаты статусы (алга таба – депутат) Россия ФедерациясеКонституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы Уставы (алгатаба – район Уставы), әлегеНигезләмә нигезендә билгеләнә.

2.Җирле үзидарә органнары депутатның гамәлдәге законнар, район Уставы һәм әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән хокук һәм бурычларын нәтиҗәле тормышка ашыру өчен шартлар тудыралар.

**2маддә. Депутат вәкаләтләре срогы**

1.Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы(алга таба – район) составына керүче җирлек башлыгы вазыйфасына керешкән көннән яисә әлеге җирлекнең вәкиллекле органы депутатының составына әлеге җирлек кергән район Советы депутаты булып сайланган көннән тиңдәшле рәвештә депутатның вәкаләтләре башлана һәм,әлеге Нигезләмәнең 3 маддәсендә каралган очраклардан гайре, җирлекнең яңа сайланган башлыгы вазыйфасына керешкән көннән яисә әлеге җирлектән булган депутатның район Советы составына чираттагы сайлануы турындагы карар үз көченә кергән көннән тиңдәшле рәвештә туктала.

2.Депутат вәкаләтләре срогы ике елдан ким һәм биш елдан артык була алмый.

**3 маддә. Депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. Депутат вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) вафат булу;

2) үз теләге буенча хезмәттән китү(отставка);

3) суд тарафыннан юридик хокукларга сәләтсез яки юридик хокукларгачикләнгән сәләтсез дип танылу;

4)суд тарафыннан билгесез булмаучы дип яки үлгән дип игълан ителүе танылу;

5)судның аңа карата гаепләү карарының закон көченә керүе;

6)Россия Федерациясеннән читкә даими яшәү урынына чыгып китү;

7)Россия Федерациясегражданлыгы туктатылу, аның нигезендә чит ил гражданына җирле үзидарә органына сайланырга, чит дәүләт гражданлыгын булдырырга яисә Россия Федерациясе гражданына Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашмаучы чит дәүләт территориясендә даими яшәүгә хокукын раслаучы паспорт яки аның нигезендә чит ил гражданлыгына ия булган Россия Федерациясе гражданына җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирүче башка документ алырга хокук бирүче Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданлыгының туктатылуы;

8)район составына керүче җирлекнең тиңдәш вәкиллекле органы депутаты буларак сайлаучылар тарафыннан чакыртып алу;

9)район Советы вәкаләтләренең вакытыннан алда туктатылуы яисә җирлек башлыгы буларак яки җирлекнең тиңдәш вәкаләтле органы депутаты буларак вәкаләтләренең вакытыннан алда туктатылуы;

10)хәрби хезмәткә чакырылу яки аны алыштыручы альтернатив граждан хезмәтенә җибәрелү;

11)федераль законнарда билгеләнгән башка очракларда.

2.2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү очрагында депутат вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.

3.Депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында район Советының карары вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигезнең барлыкка килү көненнән 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә, ә бу нигез район Советы утырышлары арасындагы чорда барлыкка килсә – мондый нигез барлыкка килгән көннән өч айдан да соңга калмыйча.

4.Татарстан Республикасы Президенты депутатның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы белдерү белән мөрәҗәгать иткән очракта вәкаләтләрне вакытыннан алда туктатуга нигезнең барлыкка килү көне булып әлеге белдерүнең район Советына керү көне тора.

5. Әлеге маддәнең 1 өлеше 1 – 7 пунктларында каралган нигезләр буенча депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы мәсьәлә район Советы тарафыннан депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен нигез кергәннән соң аның чираттагы утырышында карала.

6.Әлеге маддәнең 1 өлеше 1 – 7 пунктларында каралган нигезләр буенча депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату район Советының депутат вәкаләтләрен туктату көне күрсәтелгән карар белән рәсмиләштерелә.

7.Депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату очрагында барлыкка килгән буш депутат мандаты урынын алмаштыру гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**4 маддә.Депутат таныклыгы һәм күкрәк билгесе**

1.Депутат үзенең вәкаләтләре срогы дәвамында файдалана торган аның шәхесен һәм вәкаләтләрен раслаучы төп документка – таныклыкка, шулай ук күкрәк билгесенә ия.

2.Депутат таныклыгы һәм күкрәк билгесе турындагы Нигезләмә, аларның үрнәкләре һәм тасвирламалары район Советы тарафыннан раслана.

**5 маддә. Депутат эшчәнлеген тормышка ашыру шартлары**

1.Үз вәкаләтләрен тоткарлыксыз тормышка ашыру өчен депутатка шартлар тәэмин ителә.

2.Депутатлар үз вәкаләтләрен, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм район Уставында билгеләнгән очраклардан гайре,кагыйдә буларак, даими булмаган нигездә гамәлгә ашыралар

3.Депутат башка муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты яки башка муниципаль берәмлек җирле үзидарәсенең сайлап куела торган вазыйфаи зат вәкаләтләрен, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан гайре, бер үк вакытта башкара алмый.

4.Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутат тиеш түгел:

1)эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, коммерция оешмалары белән идарә итүдә яки коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы, муниципаль

берәмлекләрнең башка берләшмәләре, сәяси партияләр идарә итүендә катнашудан, башка җәмәгать оешмасы, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, җиләк-җимеш, яшелчә үстерү бакчачылыгы, дача кулланучылар кооперативлары, күчемсез милек хуҗалары ширкәтләре корылтаенда (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан гайре),Россия Федерациясе Президенты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез нигездә катнашудан; гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендәтүләүсез нигездәмуниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен оешманы яки муниципаль милектә булганакцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарәне гамәлгә куючы вәкаләтләренмуниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актларга туры китереп тәкъдим итүдән; федераль законнарда каралган башка очраклардан гайре;

2) мөгаллимлек, фәнни һәм бүтән иҗади эшчәнлектән гайре, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шуның өстенәмөгаллимлек , фәнни һәм бүтән иҗади эшчәнлек,әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яки Россия Федерациясе законнары тарафыннан башкасы каралмаган булса, фәкать чит дәүләтләр, халыкара һәм чит илләр оешмалары, чит илләр гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар средстволары исәбеннән финансланырга тиеш түгел;

3)әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яки Россия Федерациясезаконнарында башкасы каралмаган булса,чит илләрнең коммерциячел дә, хөкүмәтнеке дә булмаган оешмаларының һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эш итүче структура подразделениеләренең идарә органнары, попечительләр яисә күзәтүчеләр советлары, башка органнар составына керергә.

5.Депутат 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында”гы 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, йөкләмәләрен башкарырга тиеш.Депутат вәкаләтләре 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында”гы273-ФЗ номерлы Федераль законда, 2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазыйфаларын алмаштыручы затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүенә контроль турында”гы 230-ФЗ номерлы Федераль законда, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларындахисаплар ачуны һәм (кертемнәргә) ия булуны, булган акча средстволарын һәм хәзинәләрне саклауны, ия булуны һәм (яки) чит илләр финанс инструментларыннан файдалануны тыю турында”гы 79-ФЗФедераль законда каралган чикләүләрне, тыюларны үтәмәгән, бурычларын башкармаган очракта вакытыннан алда туктатыла.

6.Депутат тарафыннан, Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы законнарына туры китереп, керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре хакында бирелгән мәгълүматларының дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Президенты карары буенча Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

7.Әлеге маддәнең 6 өлешенә туры китереп үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында”гы 273-ФЗ номерлы Федераль закон,2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазыйфаларын алмаштыручы затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүенә контроль турында”гы 230-ФЗ номерлы Федераль закон,2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларында хисаплар ачуны һәм (кертемнәргә) ия булуны, булган акча средстволарын һәм хәзинәләрне саклауны, ия булуны һәм (яки) чит илләр финанс инструментларыннан файдалануны тыю турында”гы 79-ФЗ Федераль законнар тарафыннан билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, бурычларны үтәмәү фактларыбеленгәндә,Татарстан Республикасы Президенты депутатның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындатиешле карарны кабул итәргә вәкаләтле булган район Советына яисә судка белдерү белән мөрәҗәгать итә.

8.Депутатлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында бирелгән мәгълүматларыТатарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла һәм (яки) муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә халыкка игълан итү өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла.

9.Вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутат граждан, административ яки җинаять эше яисә административ хокук бозулар эше буенча яклаучы яки вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан гайре) сыйфатында катнаша алмый.

10.Депутат статусы белән бәйле башка чикләүләрфедеральзаконнар белән билгеләнә.

**6 маддә.Депутатның эшчәнлек формалары**

1.Депутатлар үзләренең эшчәнлекләрен түбәндәге формаларда гамәлгә ашыралар:

1) район Советы утырышларында катнашу;

2) район Советының даими һәм вакытлы комиссияләре, эшче төркемнәре эшләрендә катнашу;

3) район Советы каравынарайон Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә муниципаль норматив-хокукый актлар һәм аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектлары кертү;

4) депутат таләбе кертү;

5)җирле үзидарә органнарына, иҗтимагыйберләшмәләргә һәм аларның вазыйфаи затларына тәкъдимнәр кертү;

6) депутат мөрәҗәгате җибәрү;

7)сайлаучылар белән эш;

8)территориальҗәмәгатьүзидарәсен оештыруда катнашу;

9)район Советында депутатлар берләшмәләре (фракцияләре) һәм депутатлар төркемнәре эшендә катнашу;

2.Депутат үз эшчәнлеген федеральзаконнарда, Татарстан Республикасызаконнарында, район Уставында, район Советы Регламентында, башкамуниципальхокукыйактлардакаралган башка формаларда гамәлгә ашырырга мөмкин.

**7 маддә. Район Советында фракцияләр һәм башка депутат берләшмәләре**

1.Сәяси фиркаләр (аларның региональ бүлекчәләре яки башка структур подразделениеләре) күрсәткән кандидатлар исемлеге составында сайланган депутатлар,әлеге маддәнең 6 өлешендә каралган очрактан гайре, депутат берләшмәләренә (фракцияләргә) (алга таба – фракция) керәләр. Фракция үз эченә тиңдәшле кандидатлар исемлеге составында сайланган барлык депутатларны (депутатны) ала.Фракцияләргә шулай ук бер мандатлы яки күп мандатлы округлар буенча сайланган депутатлар да һәм әлеге маддәнең 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси фирка (аның региональ бүлекчәсе яисә бүтән структур подразделениесе)кандидатлары исемлеге составында сайланган депутат (депутатлар) да керергә мөмкин.

2.Фракцияләрнең эшчәнлек тәртибе Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 45-ТРЗ номерлы законы һәм район Советы Регламенты белән билгеләнә.

3.Фракциянең тулы исеме булып кандидатлар исемлеге составында тиңдәшле депутатлар сайланган сәяси фирка уставында күрсәтелгән исем тора. Фракция фракция турындагы нигезләмәдә билгеләнгән аның тулы исеменә тәңгәл килә торган кыска исем булдырырга хокуклы.

4. Фракцияләр район Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә хәбәрнамә белән теркәлергә тиеш.

Яңа теркәлгән фракция турында мәгълүматлар, шулай ук күрсәтелгән фракциягә керүче депутатлар (депутат) турындагы мәгълүматлар район Советының фракцияне теркәүдән соңгы беренче утырышында игълан ителә.

5.Фракциянең эчке эшчәнлеге аның тарафыннанфракциянең оештыру җыелышында тиңдәшле кандидатлар исемлеге составында сайланган депутатларның гомуми саныннан күпчелек тавыш белән расланучыфракция турындагы нигезләмәгә туры китереп мөстәкыйль рәвештә оештырыла.

6.Сәяси фирканең бетерелү яки үзгәртеп кору белән бәйле рәвештә эшчәнлеге туктатылган очракта аның район Советындагы фракциясенең эшчәнлеге, шулай ук депутатларның бу фракциядә әгъза булып торуы юридик затларның Бердәм дәүләт реестрына тиешле язма кертелгән көннән туктатыла.

7.Сәяси фиркаләр (аларның региональ бүлекчәләре яки башка структур подразделениеләре) күрсәткән кандидатлар исемлеге составында сайланган депутат әлеге маддәнең 1 өлеше нигезендә әгъза булып торган фракциядән чыгарга хокуксыз. Күрсәтелгән депутаткандидатлары исемлеге составында сайланган шул сәяси фирканең генә әгъзасы булып тора ала.

8.Бер мандатлы яки күп мандатлы сайлау округлары буенча сайланган һәм фракциягә керүче депутат яисә әлеге маддәнең 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси фирка кандидатлары исемлеге составында сайланган һәм фракциягә керүче депутат бары тик фракциясенә үзе кергән сәяси фирканең генә әгъзасы булып тора ала.

9.Әлеге маддәнең 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси фирка кандидатлары исемлеге составында сайланган һәм район Советында үз фракциясе булган сәяси фиркагә керүче депутат әлеге фракциягә керә һәм аннан чыгарга хокуксыз.

10.Бер мандатлы яки күп мандатлы сайлау округлары буенча сайланган һәм фракциягә керүче депутат аннан белдерү хәбәре бирү тәртибендә чыгарга хокуклы.

Депутатның фракциядә әгъза булып торуы туктатылу турындагы хәбәр район Советының әгъзалык туктатылганнан соңгы беренче утырышында игълан ителә.

11.Әлеге маддәнең 7 – 9 өлешләрендә каралган таләпләрне үтәмәү депутат вәкаләтләрен туктатуга сәбәп була.

12.Әгәр фракциягә керүче кандидатлар исемлеге составында сайланган депутатларның (депутатның) вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу анда мондый исемлек составында сайланган депутатларның (депутатның) булмавына китерсә, бу очракта күрсәтелгән фракциянең район Советында эшчәнлеге туктатыла.

Моның белән бер үк вакытта бер мандатлы яки күп мандатлы сайлау округлары буенча сайланган һәм әлеге маддәнең 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси фирка (аның региональ бүлекчәсе яисә бүтән структур подразделениесе) кандидатлары исемлеге составында сайланган депутатлар аның составына кергән андый фракциядә әгъза булып тору туктатыла.

13.Фракция эшчәнлегенең туктатылуы турындагы хәбәр, әлеге маддәнең 6,12 өлешләренә туры китереп, район Советының фракция эшчәнлеге туктатылганнан соңгы беренче утырышында игълан ителә.

14.Бер мандатлы яки күп мандатлы сайлау округлары буенча сайланган һәмфракцияләргә кермәгән депутатлар һәм әлеге маддәнең 6 өлешендә күрсәтелгән сәяси фирка (аның региональ бүлекчәсе яисә бүтән структур подразделениесе) кандидатлары исемлеге составында сайланган һәм фракцияләргә кермәгән депутатлар фракцияләр булмаган депутат берләшмәләре оештырырга мөмкин. Күрсәтелгән депутат берләшмәләре фирка, территория, һөнәри яки бүтән билгеләр буенча төзелә. Мондый депутат берләшмәләренең эшчәнлек тәртибе район Советы Регламенты белән билгеләнә.

15.Барлык депутат мандатлары да бер мандатлы һәм (яки) күп мандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатлар тарафыннан алмаштырылучы депутатлар фракцияләр булмаган депутат берләшмәләре оештырырга мөмкин.Күрсәтелгән депутат берләшмәләре фирка, территория, һөнәри яки бүтән билгеләр буенча төзелә. Мондый депутат берләшмәләренең эшчәнлек тәртибе район Советы Регламенты белән билгеләнә.

16.Депутат бер генә депутат берләшмәсендә торырга хокуклы.

**8 маддә. Депутат этикасы**

1. Депутат катгый төстә закон, этика һәм мораль нормаларын үтәргә тиеш, аерым алганда:

1)депутатның хокукый хәленшәхсән үзенә яки якын туганнарына кагылган мәсьәләләрне хәл иткәндә башка җирле үзидарә органнарының, оешмаларның, вазыйфаи затларның, муниципальхезмәткәрләрнең һәм гражданнарның эшчәнлегенә йогынты ясау өчен файдаланмаска;

2)депутат бурычларын гадел үтәүгә шик тудырырга мөмкин булган тәртип-гадәтләрдән тыелып калырга, шулай ук үзенең репутациясенә яисә район Советы абруена зыян китерергә сәләтле низаглы вәзгыятьләрдән сакланып калырга;

3)мәнфәгатьләр низагы –депутатның шәхси кызыксынуы (турыдан-туры яисә читләтеп) аның депутат вәкаләтләрен тиешенчә, объектив һәм гадел итеп гамәлгә ашыруына йогынты ясый яки ясарга мөмкин булган вәзгыять – барлыкка килү куркынычы булганда район Советы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә килеп туган мәнфәгатьләр низагы хакында яисә аның барлыкка килү ихтималлыгы булу турында үзенә билгеле булуга ул турыда хәбәр бирергә һәм әлеге мәнфәгатьләр низагын булдырмый калуга яки җайга алуга юнәлдерелгән район Советы карарын үтәргә бурычлы;

4)халык алдында (ачык) чыгыш ясауларның район Советы тарафыннан гамәлгә кертелгән кагыйдәләрен үтәргә;

5)депутат бурычларын үтәү белән бәйле рәвештә мәгълүм булган федераль законнар нигезендә сер итеп саклана торган мәгълүматларга кертелгән мәгълүматларны ачып салмаска һәм депутатлык эшчәнлеге белән бәйле булмаган максатларда файдаланмаска;

6)депутат бурычларын үтәү белән бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан (бүләкләр, акчалата түләүләр, ссудалар, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачуларга, ял итүләргә, транспорт чыгымнарына түләүләр һәм башка бүләкләр) бүләкләүләр алмаска;

2.Депутат этикасын бозган очракта депутатның тәртибе турындагы мәсьәлә район Советы йөкләмәсе буенча тиешле комиссия тарафыннан карала.

**9 маддә. Депутатның район Советы утырышларында катнашуы**

1.Депутат район Советы утырышларында шәхсән үзе катнаша.

2.Депутатка үзвакытында, әмма тиешле утырышны үткәрү көненә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча, район Советы утырышын үткәрү вакыты һәм урыны хакында, аның каравына кертелүче мәсьәләләр турында хәбәр ителә, шулай ук депутат район Советы Регламенты нигезендә әлеге мәсьәләләр буенча барлык кирәкле материалларны ала.

Депутат район Советы утырышында катнашу мөмкинчелеге булмаганда алдан, ләкин тиешле утырыш башланырга 2 сәгатьтән дә соңга калмыйча, ул турыда район Советы аппаратына хәбәр итә.

3.Депутат хокуклы:

1) комиссиядә һәм район Советында тиешле вазыйфаларга сайларга һәм сайланырга;

2)район Советында карау өчен мәсьәләләр тәкъдим итәргә;

3)район Советы тарафыннан булдырылучы органнарны төзү мәсьәләләре һәм район Советы тарафыннан сайлана (билгеләнә, килештерелә) торган вазыйфаи затлар кандидатуралары буенча фикерен белдерергә;

4)хокук эшләү инициативасын тормышка ашыру тәртибендә район Советына хокук актлары проектларын кертергә;

5) көн тәртибе буенча фикер алыша торган мәсьәләләрнең асылы һәм карау тәртибе буенча тәкъдим һәм фикерләр, район Советының карар проектларына һәм башка актларына төзәтмәләр кертергә;

6)район Советына хисап тотарга тиешле яки аның контролендә булган теләсә кайсы орган

яисә вазыйфаи затның чираттан тыш хисабын яки хәбәрен район Советы утырышында тыңлау хакында тәкъдим кертергә;

7)билгеләнгән тәртиптә фикер алышуларда катнашырга;

8)гражданнарның аның фикеренчә иҗтимагый әһәмияткә ия булган мөрәҗәгатьләрен район Советы утырышларында игълан итәргә;

9)тавыш бирү сәбәпләре буенча да үзенең тәкъдимнәрен нигезләп чыгыш ясарга, белешмәләр һәм аңлатмалар бирергә;

10)район Советы беркетмәләренең эчтәлеге белән танышырга.

4.Депутатның район Советы утырышында әйтелгән тәкъдим һәм фикерләре район Советының тиешле комиссиясе тарафыннан карала һәм фикер алышына.

**10 маддә. Депутатның бурычлары**

1. Депутат тиеш:

1)үзенең эшчәнлеген гамәлгә ашырганда РоссияФедерациясе Конституциясен, федеральзаконнарны,ТатарстанРеспубликасы Конституциясен, ТатарстанРеспубликасы законнарын, район Уставын, бүтән муниципальхокукыйактларны үтәргә;

2)гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне һәм яклауны тәэмин итәргә;

3)гамәлдәге законнар нигезендә үзвакытында гражданнарның, аларның оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмаларның, иҗтимагый берләшмәләрнең, дәүләт хакимияте органнарының , җирле үзидарә органнарының мөрәҗәгатьләрен карарга һәм үзенең эш йөртергә хакы булган өлкә чикләрендә аларга җавап бирергә;

4)депутатлык вәкаләтләрен гамәлгә ашыру белән бәйле чикләүләрне үтәргә;

5)әхлак һәм депутат этикасы нормаларын үтәргә;

6)даими рәвештә айга бер мәртәбәдән дә ким булмаган санда сайлаучылар кабул итүне үткәрергә;

7)турыдан-туры очрашуларда сайлаучылар алдында хисап тотарга, шулай ук елга бер тапкырдан да ким булмаган санда массакүләм мәгълүмат чаралары аша аларга үзенең эше хакында хәбәр итәргә;

8)дәүләт һәм башка закон белән саклаучы серне сакларга, шулай ук депутатлык вәкаләтләрен гамәлгә ашыру белән бәйле рәвештәаңа мәгълүм булган гражданнарның шәхси тормышына, намусына һәм дәрәҗәсенә кагылган мәгълүматларны таратмаска;

2.Депутат аңа федеральзаконнар,ТатарстанРеспубликасы законнары, район Уставы һәм бүтән муниципальхокукыйактлар тарафыннан йөкләнгән башка бурычларны үти.

**11 маддә. Депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чикләүләр**

1.Депутат тиеш түгел:

1)депутат бурычларын үтәү белән бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан (бүләкләр, акчалата бүләкләүләр, ссудалар, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачуларга, ял итүләргә, транспорт чыгымнарына түләүләр һәм башка бүләкләр) бүләкләүләр алырга;

2)гамәлгә ашырылучы вәкаләтләр чикләрендә аерым сәяси фиркаләргә, сайлау берләшмәләренә, шулай ук дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларда аерым депутатларга өстенлекләр тәэмин итүче карарлар кабул итәргә;

3)үзенең вәкаләтләрен тормышка ашыру процессында, шулай ук җирле бюджет чаралары хисабына финанс ташламалары һәм гарантияләр биргәндә башлангыч капиталында депутатның милек өлеше (акцияләр пакеты) булган яки депутат анда катнашучы яисә аның әгъзасы булып торган аерым затларга һәм оешмаларга башкаларга караганда артыграк өстенлек күрсәтергә;

4)депутат вәкаләтләрен тормышка ашыру белән бәйле командировкаларга, гамәлдәге Россия Федерациясе законнары, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләренә туры китереп яки дәүләт хакимиятенең федераль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте

органнары, җирле үзидарә органнарының чит ил партнерлары белән төзелгән килешүләре нигезендә гамәлгә ашырылучы командировкалардан гайре,физик һәм юридик затлар хисабыначыгарга;

2.Депутат вәкаләтләрен тормышка ашыру белән бәйле бүтән чикләүләр федераль законнар белән гамәлгә кертелергә мөмкин.

**12маддә. Депутатның район Советының даими һәм вакытлы комиссияләре эшендә катнашуы**

1. Депутат район Советының үзе әгъза булып торган даими һәм вакытлы комиссияләрендә каралучы барлык мәсьәләләр буенча тавыш биргәндә хәлиткеч тавыш хокукыннан файдалана.

2.Депутат район Советының даими һәм вакытлы комиссияләре утырышларында үзенә Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль закон, Татарстан Республикасы законнары, район Уставы, район Советы Регламенты һәм әлеге Нигезләмә нигезендә бирелгән хокукларын реализацияли.

3.Депутат район Советының үзе әгъза булып торган даими һәм вакытлы комиссияләре эшендә шәхсән катнаша, тәкъдимнәр кертә, район Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә карала торган сорауларны тикшерүдә һәм карарлар кабул итүдә катнаша.Нигезле сәбәп буенча күрсәтелгән утырышларда катнашырга мөмкинчелеге булмаган очракта депутат алдан тиешле утырыш башланырга 2 сәгатьтән дә соңга калмыйча ул турыда район Советының тиңдәшле даими һәм вакытлы комиссиясе рәисенә хәбәр итә.

4.Депутат район Советының үзе әгъза булып тормаган комиссияләр эшендә катнашырга, тәкъдимнәр кертергә, карала торган сорауларны тикшерүдә һәм карарлар кабул итүдә фикер алышу хокукына ия тавыш белән катнаша ала.

**13 маддә. Депутатның район Советы һәм аның комиссияләренең йөкләмәләрен үтәүдә катнашуы**

1. Депутат район Советы һәм аның комиссияләренең аңа эш йөртергә хакы булган өлкә чикләрендәбирелгән йөкләмәләрен үтәргә бурычлы.

2.Район Советы яки аның комиссияләре йөкләмәләре буенча депутат районның җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, районның җирле бюджет чаралары исәбенә тулысынча яки өлешчә финансланучы яисә гамәлгә куючылары сыйфатында җирле үзидарә органнары булган һәм район территориясендә урнашкан оешмалар тарафыннан район Советы карарларының үтәлүен тикшерүдә катнаша.

3.Йөкләмәләрне үтәү нәтиҗәләре хакында депутат район Советына яки аның комиссияләренә хәбәр итә.

**14 маддә. Депутат таләбе**

1.Район Советы утырышларында депутат районның җирле үзидарә органнарына,районның җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына, район Советы тарафыннан төзелгән яки сайланган башка органнарның җирәкчеләренә, муниципальпредприятиеләрнең һәм муниципальучреждениеләрнең җитәкчеләренә аның эш йөртергә хакы булган өлкәгә керүче мәсьәләләр буенча таләпләр белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2.Депутат таләбе – депутатның район Советы карары белән депутат таләбе дип танылучы мөрәҗәгате ул. Депутат таләбе турындагы тәкъдим язмача формада депутат яки депутатлар төркеме тарафыннан кертелә һәм район Советы утырышында игълан ителә.

3.Халык алдындагы әһәмиятле функцияләрне тормышка ашыру йөкләнгән районның җирле үзидарә органы, районның җирле үзидарә органының депутат таләбе җибәрелгән вазыйфаи заты, муниципаль предприятиенең яки муниципаль учреждениенең җитәкчесе аңа язмача рәвештә депутат таләбе теркәлгән көннән 30 көннән дә соңга калмыйча җавап бирергү тиеш. Җавап

депутат таләбе җибәрелгән районның җирле үзидарә органы җитәкчесе, районның җирле үзидарә органының вазыйфаи заты, муниципаль предприятиенең яки муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан яисә аның вазыйфаларын вакытлыча башкаручы зат тарафыннан имзаланырга тиеш.

4.Таләп инициаторы таләптә куелган мәсьәләләрне карауда турыдан-туры катнашырга хокуклы. Аларны карау көне хакында таләп инициаторына алдан ук мәсьәләне карау көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителергә тиеш.

5.Район Советырайонның җирле үзидарә органына, районның җирле үзидарә органының вазыйфаи затына, муниципаль предприятиенең яки муниципаль учреждение җитәкчесенә район Советы билгеләгән срокка депутат таләбе буенча кабул ителгән карарны үтәү турында язмача җавап китерүне йөкләргә хокуклы.

**15 маддә. Депутат тәкъдимнәре**

1. Депутат тарафыннан район Советы утырышларында язмача рәвештә кертелгән тәкъдимнәр районның җирле үзидарә органнары һәм район җирле үзидарәсенең вазыйфаи затлары тарафыннан карала.

2.Депутат тәкъдимнәре җибәрелгәнрайонның җирле үзидарә органнары һәм район җирле үзидарәсенең вазыйфаи затлары аларны тәкъдим теркәлгән көннән соң 30 көн эчендә карарга һәм нәтиҗәләре хакында район Советына һәм депутатка хәбәр итәргә тиешләр. Тәкъдим кире кагылган очракта дәлилләр белән нигезләнгән җавап бирелә.

**16 маддә. . Депутат мөрәҗәгате**

1. Депутат мөрәҗәгате дип депутатның язмача рәвештә җирле үзидарә органына, муниципаль предприятиеләр һәм муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә, халык алдындагы әһәмиятле функцияләрне тормышка ашыру йөкләнгән район территориясендә урнашкан оешма һәм иҗтимагый берләшмәләргә, күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларына үзләренең компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча аның депутатлык эшчәнлеге белән бәйле хәбәрләр һәм мәгълүматлар алу максаты белән мөрәҗәгать итүе санала.

2.Депутат мөрәҗәгате депутат бланкында рәсмиләштерелә һәм депутат тарафыннан мөстәкыйль рәвештә җибәрелә.

3.Җирле үзидарә органына, муниципаль предприятиеләр һәм муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә, халык алдындагы әһәмиятле функцияләрне тормышка ашыру йөкләнгән район территориясендә урнашкан оешма һәм иҗтимагый берләшмәләргә, аларның вазыйфаи затларына кергән депутат мөрәҗәгате аларның компетенциясе нигезендә мөрәҗәгать теркәлгән көннән соң 30 көн эчендә карала һәм күрсәтелгән сроктан соңга калмыйча соралган хәбәр яки мәгълүматлар депутатка бирелә. Бу вакытта дәүләт яки кәсәбәчелек серен тәшкил иткән мәгълүматлар федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә тапшырылалар.

4. Өстәмә тикшерү үткәрү яки депутат мөрәҗәгате буенча нинди дә булса өстәмә материаллар таләп итү зарур булган гадәттән тыш очракларда мөрәҗәгатьне карау срогы аны теркәгән көннән 30 көнгә чаклы озайтыла. Әлеге маддәнең 3 өлешендә күрсәтелгән вазыйфаи затлар депутатка аның мөрәҗәгатен карау срогының озайтылуы хакында хәбәр итәргә тиешләр.

5. Депутат аның тарафыннан мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне карауда турыдан-туры катнашырга хокуклы.Аларны карау көне хакында депутатка алдан өч календарь көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителергә тиеш.

6. Депутат мөрәҗәгатенә җавап мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча булырга һәм мөрәҗәгать җибәрелгән вазыйфаи зат яисә аңа вәкаләте булган зат тарафыннан имзаланырга тиеш.

7. Әгәр җавап җибәрелгән депутат мөрәҗәгатенең асылы буенча бирелмәсә яисә мөрәҗәгатькә җавап вәкаләте булмаган зат тарафыннан имзаланган булса, депутат тәкъдиме буенча аның мөрәҗәгатенә җавап район Советы Регламенты нигезендә мөрәҗәгать җибәрелгән вазыйфаи затны чакырып район Советының даими комиссиясе утырышында каралырга мөмкин.

**17маддә. Депутатның сайлаучылар белән үзара мөнәсәбәте**

1. Депутат район (сайлау округы) сайлаучылары белән, шулай ук аның сайлау округында урнашкан предприятие коллективлары, оешмалар, дәүләт һәм бүтән органнар, җирле үзидарә органнары белән элемтәдә тора.

2. Депутат сайлаучылар каршында җаваплы һәм алар алдында хисап тота.

3.Сайлаучылары алдында депутат үзенең эше турында елга бер мәртәбәдән дә ким булмаган санда хисап тота, шулай ук айга бер мәртәбәдән дә ким булмаган санда үзенең сайлау округы сайлаучыларын кабул итүне үткәрә.

4.Депутат үз сайлаучыларының хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча чаралар күрә: алардан кергән тәкъдим, мөрәҗәгать һәм шикаятьләрне карый, үзенең вәкаләтләре чикләрендә аларда булган сорауларны дөрес хәл итәргә булыша; гражданнарны кабул итүне алып бара; җәмәгатьчелек фикерен өйрәнә һәм зарурлык булганда тиешле җирле үзидарә органнарына һәм иҗтимагый берләшмәләргә, аларның вазыйфаи затларына тәкъдимнәр кертә.

5.Депутатның сайлаучылар белән очрашулары биналарда, махсус билгеләнгән урыннарда, шулай ук ишегалды эчендәге территорияләрдә үткәрелә шундый шарт белән – аларны үткәрү яшәү шартларын тәэмин итүче объектларның, транспорт яки социаль инфраструктураның, элемтәнең эшләвен бозуга китермәсә, җәяүлеләр һәм (яки) транспорт чараларының яисә гражданнарның торак биналарга яки транспорт яисә социаль инфраструктура объектларына үтүенә комачаулык тудырмаса. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының яки җирле үзидарә органнарының мондый очрашулар хакында белдерү хәбәре таләп ителми. Бу вакытта депутат күрсәтелгән органнарга аларны үткәрү датасы һәм урыны турында алдан хәбәр бирергә хокуклы.

6.Районның Башкарма комитеты депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус урыннар билгели, шулай ук депутатларның сайлаучылар белән очрашулар уздыру өчен районның җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган биналарның исемлеген һәм аларны бирү тәртибен аныклый.

7.Депутатның сайлаучылар белән очрашулары ачык чара рәвешендә Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, тантаналы йөрешләр, пикетлар оештыру турындагы гамәлдәге законнары нигезендә уздырыла.

8.Депутатныңсайлаучылар белән Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, тантаналы йөрешләр, пикетлар оештыру турындагы гамәлдәге законнары белән билгеләнгән ачык чара рәвешендә очрашулар оештыруына яки үткәрүенә комачаулау Россия Федерациясе законнары нигезендә административ җаваплылыкка сәбәп була.

**18 маддә.Депутатның беренче чиратта кабул ителүгә хокукы**

Депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча депутат район җирле үзидарә органнары,районның җирле бюджет чаралары хисабына тулысынча яисә өлешчә финанслаучы яисә гамәлгә куючылары сыйфатында район җирле үзидарә органнары булган һәм район территориясендә урнашкан оешмаларныңҗитәкчеләре һәм башка вазыйфаи затлары тарафыннан беренче чират тәртибендә кабул ителү хокукыннан файдалана.

**19 маддә. Депутатның мәгълүматны алуга һәм таратуга хокукы**

Район Советы аппаратының вазыйфаи затлары депутатны район Советы Регламенты белән билгеләнгән тәртиптә район Советына кергән документлар белән тәэмин итәләр.

**20 маддә. Депутатның районның җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәте**

1. Депутат район Советы, аның органнары эшчәнлегендә актив катнашуын тәэмин итүче хокукларның бөтен тулылыгына ия.

2.Район Советы депутатның сайлау округындагы эше, аның район Советы, аның органнары карарларын һәм йөкләмәләрен үтәве турындагы хәбәрен тыңларга хокуклы.

3. Районның җирле үзидарә органнары һәм район җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары депутатка аның эшендә кирәкле ярдәмне күрсәтәләр, депутатка районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеге хакында, районның социаль-икътисади үсеш стратегиясенен үтәү барышы турында, депутатның тәнкыйть фикерләре һәм тәкъдимнәре буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүмат ирештерәләр, депутатка гамәлдәге законнарны, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарының эш тәҗрибәсен, җәмәгатьчелек фикерен өйрәнүдә булышлык күрсәтәләр.

**21 маддә. Депутат эшчәнлеген гамәлгә ашыру гарантияләре**

1.Депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре федеральзаконнарһәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә район Уставы белән билгеләнә.

2. Депутатларны җинаять яки административ җаваплылыкка тартканда,тоткарлаганда,кулга алганда, тентегәндә, сорау алганда, аларга карата бүтән җинаять-процессуаль һәм административ-процессуаль гамәлләр кылганда, шулай ук депутатларга, аларның торак һәм (яки) хезмәт биналарына, багажларына, шәхси һәм хезмәт урынындагы транспорт чараларына , язышуларына, файдалана торган элемтә чараларына, алар карамагындагы документларга карата оператив-эзләү чаралары үткәргәндә аларның хокук гарантияләре федераль законнар белән билгеләнә.

3.Депутат әйтелгән фикере, тавыш биргәндәгепозициясе һәм депутат статусына туры килә торган башка гамәлләре өчен, шул исәптән вәкаләтләр срогы чыккач та җинаять яки административ җаваплылыкка тартыла алмый. Әлеге нигезләмә депутат тарафыннанкылынганфедераль законнар белән җаваплылык каралган халык алдында мыскыллау, яла ягу яисә бүтән хокук бозулар очракларына кагылмый.